Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

# Татарстан КОММУНИСТЫ

№5-6 (29-30). 2012 ел, 20 июль. КПРФның Татарстан региональ бүлеге иҗтимагый-политик газетасы

## КПРФ Үзәк Комитеты пленумы



30 июнь көнне КПРФ Үзәк Комитетының XIII (июнь) пленумы булып узды. Пленумда катнашучылар «Хәзерге заман шартларында партиянең башлангыч һәм җирле бүлекләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү турында»гы мәсьәләне карадылар.

Пленум эше традиция буенча КПРФның яңа членнарына партия билетлары тапшырудан башланып китте. Партия сафларына яңа килүчеләр арасында укытучылар, инженерлар, программистлар, эшмәкәрләр, авыл хуҗалыгы һәм хезмәт күрсәтү сфералары хезмәтчәннәре, югары һәм махсус урта белем бирүче уку йортлары студентлары бар.

Докладның пленум алдыннан басылып чыккан идеяләре белән кыскача гына КПРФ Үзәк Комитеты председателе Геннадий Андреевич Зюганов таныштырды.

## КПРФның Татарстан рескомының XI пленумы

3 июнь көнне КПРФ Татарстан региональ бүлеге рескомының XI пленумы узды.

Республика комитеты беренче секретаре Х.Г. Миргалимовның «Партия дисциплинасын ныгыту, демократик централизм принципларын саклау буенча КПРФның Татарстан республика комитеты, Татарстан региональ бүлеге башлангыч һәм җирле бүлекчәләренең бурычлары турында»гы докладын тыңлап, фикер алышканнан соң ресском пленумы Җиһаншин, Вәлиев, Буторин, Рыбаков, Иосипов, Лазарев, Терехин, Әхмәтов, Гыйбадуллин, Беляевларның Уставта каралмаган партия җыелышлары үткәрүгә актив керешеп китүләрен билгеләп үтте. Үз «партҗыелышлары» алар Казан шәһәрендәге Киров, Яңа Савин, Совет районнарында «КПРФның район комитетларын» сайлап куйганнар. Гурьева, Потанкин, Фазлыева, Кормилицын (Чаллы шәһәре), Максимов (Түбән Кама) йогынтысында көч туплаган шушы ук төркем КПРФның Татарстан региональ бүлеге рескомын да «сайлап куйган» иде инде.

Югарыда саналган затларның Уставта каралмаган гамәлләр кылуына бәйле рәвештә, КПРФның Татарстан региональ бүлеге республика комитеты, күпчелек тавыш белән кабул ителгән карарында, атап әйткәндә, мондый фикерләрне билгеләп үтте: «Казан шәһәрендәге Киров, Яңа Савин, Совет районнарында КПРФның Татарстан региональ бүлекләре район комитетлары җитәкчеләрен кабат сайлап кую өчен КПРФ Уставын тупас бозып, легитим булмаган рәвештә үткәрелгән «партҗыелыш» дип аталган җыеннарын дөрес түгел дип табарга».

Реском пленумы шулай ук «Казан шәһәре җирле бүлекләрендәге вәзгыятькә ачыклык кертү өчен Казан шәһәр комитеты һәм шәһәр районнарындагы комитетлар членнарыннан торган комиссия оештырырга» карар кылды.

Пленумның йомгаклау өлешендә делегатлар барысы бертавыштан диярлек (делегатларның берсе тавыш бирүдән читләшеп калды, тагын берсе исә каршы тавыш бирде) КПРФның Татарстан региональ бүлеге беренче секретаре Хафиз Гаяз улы Миргалимовка партия-политик ышаныч белдерделәр.

**Хөрмәтле иптәшләр!**

Татарстан Республикасы мөселманнарының дин башлыклары: ТР мөселманнарының Диния нәзарәте бүлеге начальнигы В.М. Якупов һәм Татарстан Диния нәзарәте идарәсе председателе И.Ә. Фәизовка карата коточкыч җинаять эшләнүе турындагы фаҗигале хәбәрне республикабыз коммунистлары бик авыр кабул итте. Төрле диннәр арасында татулык һәм теләктәшлек хакимлек иткән Казан мондый көчләү актларын белми иде әле.

Без республика җитәкчелеге һәм федераль үзәк әлеге золымны башкарган вәхшиләрне тиз арада табар өчен барысын да эшләр дип ышанабыз. Аларга җәза кырыс булырга тиеш: дини һәм политик террорчылык күренешләренә күпмилләтле Россия территориясендә урын юк!

## ТЕРРОРГА – ЮК!

### Татарстан Республикасы коммунистлары белдерүе



Бер үк вакытта бездә законлы сорау да туа: властьтагылар һәм махсус хезмәтләр мондый җинаятьне алдан күреп, аны булдырмый калыр өчен барысын да эшләделәр микән?

Татарстан Республикасы коммунистлары гомере вакытсыз һәм фаҗигале тәстә өзелгән Вәлиулла хәзрәт Якуповның туганнарының, якыннарының олы кайгысын уртаклашалар, ә Илдус хәзрәт Фәизовның тизрәк савыгуын телиләр.

**Х.Г. МИРГАЛИМОВ, КПРФның Татарстан рескомы беренче секретаре.**
**КПРФның Татарстан рескомы бюросы членнары.**
**ТР Дәүләт Советының КПРФ фракциясе депутатлары.**

## Ж.И. Алфёров – Казанда

26 июньдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов РФ Дәүләт Думасының КПРФ фракциясе депутаты, Нобель премиясе лауреаты, Россия фәннәр академиясе вице-президенты, Россия фәннәр академиясенең Санкт-Петербург фәнни үзәге президиумы председателе Жорес Алферов белән очрашты. Жорес Алферов «Наноструктуралар: физика һәм технология» XX халыкара симпозиумында катнашу кысаларында Казанда иде.



Очрашу вакытында Рөстәм Миңнеханов һәм Жорес Алферов тулаем Россиядә һәм, аерым алганда, Татарстанда фундаменталь һәм гамәли фәннең үсеш мәсьәләре турында сөйләштеләр.

**Артем ПРОКОФЬЕВ, ТР Госсоветы депутаты.**


## В.П. Пешков – Татарстанда



13 июньдә РФ Дәүләт Думасының КПРФ фракциясе депутаты, социология фәннәре докторы, КПРФ Үзәк Комитеты председателе киңәшчесе Виктор Петрович Пешков Татарстанда булды. Бигеш аэропортында аны КПРФның Татарстан республика комитеты члены, «Татарстан коммунисты» республика газетасының баш редакторы, депутатның Татарстандагы ярдәмчесе Хәким Гыйләҗев каршылады һәм озата йөрде. Россия депутаты Сарман район советы депутаты, даими комиссия председателе, КПРФның Сарман рикомы беренче секретаре Хәмзә Фәрукшин белән очрашты, район тормышы белән кызыксынды.

В.П. Пешков Азнакай район хакимиятендә булды, җирле коммунистлар белән очрашты һәм сайлаучыларны кабул итте. Сайлаучыларга бу хакта алдан район матбугаты аша хәбәр ителгән иде.

**Риф СӘЙФУЛЛИН, КПРФ члены, хезмәт ветераны.**



**В. Ленин ролендә Шәүкәт Биктимеров (Н. Погодинның «Баһадирлар» спектакле).**

## СССРның халык артисты ШӘҮКӘТ БИКТИМЕРОВ вафат

Татарлар арасындагы шундый югары исемне йөрткән иң соңгы артистыбыз 28 май көнне 83 яшендә арабыздан китте. Ул 1928 елның 28 октябрендә Казан шәһәрендә туа, Татарстанның Саба районы Миңгәр авылында үсә. 1949 елда Казан театр училищесын тәмамлый һәм Татар академия театрында эшли башлый. Шул ук елны армиягә алына. Театрга яңадан 1953-1954 елгы сезон башында кайта.

Шәүкәт Биктимеровның рольләре шактый булды. Барысы да зур рольләр: Ленинннан башлап (1970), Туктамыш ханга кадәр уйнады. Даһи артист иде. Аның иҗат юлы уңышлы булды. Кешеләрнең күңелләрендә ул җор телле, киң һәм шат күңелле, тормышны яратучы Әлмәндәр карт (1976) булып калачак.

Шәүкәт Хәсәнович Биктимеров – милли театрның иң аталы сәхнә остасы, күпкырлы иҗади шәхес, татар сәхнәсенең реалистик традицияләрен дәвам итеп, төрле характерда дистәләрчә төп образлар иҗат иткән күренекле артист. Сәхнә сөйкемлелеге, күңелгә үтеп керүче мөлаем гадилек, җылылык, йомшак лирика – артистның үзенә генә хас булган иҗади йөзе шундый.

Ш. Биктимеров 1958 елдан Коммунистлар партиясе члены иде. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1967), ТАССРның (1968), РСФСРның (1970), СССРның (1977) халык артисты, РСФСРның К. Станиславский исемендәге дәүләт бүләге лауреаты. Татарстан Фәннәр Академиясенең почетлы члены (2007).



## Шәүкәт Биктимеров белән әңгәмә

**– Әле менә өстәлегездә комсомол оешуга 90 ел тулу уңаеннан чыгарылган күкрәк билгесе ята. Әлеге бүләк юкка гына бирелмәгәндер, чөнки сезгә пионер Чашкиннан башлап, партия җитәкчеләрен дә ышаныч тапшырганнар. Хәтта юлбашчы Ленинны да. Ленин образын уйнау ничек булды икән, шул хакта тулырак сөйләсәгез иде?**

– Җитмешенче елда, Ленинның туууына 100 ел тулу уңаеннан, бөтен СССР, хәтта милли театрлар да аңа багышлап спектакль куйган иде. Шул исәптән безнең театр да. Милли театрларга да ул чакта Ленин ролен бары тик Мәскәү рөхсәте белән генә артист билгеләнде. Чөнки үз театрыбызның режиссеры гына мондый җитди рольне үзе билгели алмый иде. Шулай итеп, режиссер тәкъдиме белән, безнең театрдан СССРның халык артисты Габдулла Шамуков белән мине Мәскәүгә чакырып алдылар. Яшь вакытта Габдулла абый бу рольне Башкортостанда уйнаган булганга, баштарак Ленин ролен аңа бирергә уйлаганнар иде. Ләкин инде аның яше өлкәнрәк булганга, ахырда мине сайлап алдылар. Спектакль көн саен уйналмаса да, репертуарда 2-3 ел барды.

Шушы роль белән бәйле булган бер вакыйганы да әйтеп үтим әле. Шулай берсендә юлбашчы турындагы сәхнә әсәрен Мәскәүдә тәкъдим иттек. Гадәт буенча, спектакль ахырында бөтен артистлар тамашачыларга баш иябез. Соңыннан театр җитәкчеләре мине чакырып алды да: «Иптәш Биктимеров, бу рольдә сезнең барысы да яхшы. Ләкин Ленин икәнлегегезне онытмагыз һәм беркайчан да спектакльдән соң баш имәгез», – дип, кисәтү ясаганнар иде.

**Рәсилә КӘРИМОВА.**
10 ноябрь 2008 ел.

ИЛДӘ НИЛӘР БАР?

# Халык күпмегә түзәр?

Авылны күтәрергә кирәк дип күпме генә сөйләсәләр дә, элекке гөрләп торган күмәк хуҗалыклар юк инде ул. Таралдылар – кемгә зыяны тигән булгандыр. Хәзер менә авыл халкына эш бетте, сугыш вакытында да ябылмаган мәктәпләр ябылды, медпунктларда эшләргә кешеләр юк – медицина белгечләре авылга кайтмый. Гөрләп торган фермаларны хуҗалар, өстән кушу буенчадыр, сүтеп, сатып, таратып бетерделәр. Аерым хуҗалыклар гына 8-10ар баш сыер асрап, авылны күтәрү мөмкин хәлме соң? Дөрес, аларга дәүләт икешәр миллион сум акча тарата, ә шул ярдәмне колхозлар таралганчы, бөтен авыл халкы тулы куәткә эшләп торганда биреп булмый иде микәнни?

Күпме басу-кырлар сөрелмичә кала, җирнең беркемгә кирәге юк. Чөнки аны эшкәртергә алган техникасын, ягулыгын исәпләсәң, үстергән икмәгең алтын бәясенә төшә, ә шул ашлыкны дәүләт юк кына бәягә сатып ала. Ягулык дигәннән, анысы күмәк хуҗалык кесәсенә генә сугып калмый, һәр кешегә кагыла. Хәзер бит машина пенсионер өчен дә, инвалид кеше өчен дә кирәк нәрсә, ә 1 литр ягулыкның бәясе 30 сумга җитә. Күптән түгел генә әнә: «Бензин бәясе 14 тиенгә төште», – дип, радиодан лаф ордылар. Ничек оялмыйча хәбәр итәләр диген!

Пенсионерга, инвалидка ягулыкка бераз субсидия бирсәләр, яисә пенсияне арттырсалар, бик ярап куяр иде…

Авылларда хәзер дәвалау урыннары – хастаханәләр ябылып бетте. Хастаханәгә кереп ятып дәвалану хәзер зур проблемага әйләнде. Ятып дәвалану бәхете тәтегән очракта да, анда пенсионерларга игътибар шунын кадәр генә. Кардиология бүлекләренә эләгү бигрәк тә кыен, чөнки урын җитми, ә йөрәк-кан тамырлары чирләреннән иза чигүчеләр бик күп.

Яшьләргә эш юк, ә фатир сатып алу өчен кайсыдыр «акыллы башы» уйлап тапкан ипотека дигән нәрсә яшьләрне үлгәнче түләргә җитәрлек бурычка батыра. Советлар чорында эшләгән кешеләргә бушлай бирелгән фатирлар нишләп хәзер түләргә хәлең җитмәслек кыйммәт икән, нигә дәүләт аның 50 процентын булса да күтәрми?

Ни өчен югары уку йортларында белем алу түләүле? Укыган атлы кыланып, акча түләп кенә диплом алып чыккан табиб кешене дәвалау түгел, аны үтерергә генә сәләтле була түгелме соң?

Ни өчен мәктәп балаларын БДИ белән җәзалыйлар? Шул имтихан белән куркытылган, аны бирә алмаганнан, яисә бирә алмам дип коты очканнан үз-үзенә кул салган үсмерләрнең санын исәпкә алучылар бар микән?

Ни өчен күчемсез милек бөтенләе белән олигархлар, башлыклар кулында гына?

Пенсионерларның пенсиясен арттырабыз, дигән булалар, артмый ул, инфляция күпме булса, шуны капларлык чамада, тиенләп кенә арта.

Бу дөньяда сугыш чоры балаларының барлыгын депутатлар да, Президент та таныйрга теләми. Ни өчен? Әтиләре сугышта ятып калган, яисә хәбәрсез югалганнарның – ил өчен башын салган солдатларның балаларына да бит инде хәзер 70-80 яшь тирәсе. Алар сугыштан соңгы елларда ятимлектә, ач-ялангач булып, әтиләре әйләнеп кайткан балаларга кызыгып, кимсенеп яшәделәр. Әтиле балалар, әтиләренә бирелгән ташламалардан файдаланып, белем дә алдылар, хәзер исә оныклары машиналы, фатирлы булды. Ә үлеп калганнарның һәм хәбәрсез югалганнарның балаларына кадерле дәүләтебез нинди ярдәм күрсәтте? Аларны әллә кайчан инде тыл хезмәтчәннәренә тиң күреп, хөкүмәт кайгыртучанлык күрсәтергә тиеш, ләбаса! Илебезнең шуңа да хәле юкмыни соң? Урланган акчаларны кире кайтару турында да бер җылы сүз чыкканы юк әле элекке һәм яңа сайланган (хәер, анысы да элекке бит инде аның) Президент авызыннан…

Менә болар барысы да – халык проблемасы, социаль проблемалар. Әмма яңа сайланган Президент Путинның программасында болар турында бер генә сүз дә юк, чөнки аны үзгәртү үткәннәргә кире кайту булыр иде. Димәк, шулай булгач, халык файдасына яхшылык өмет итәсе юк, халыкны моңа кадәр ничек талаганнар, алга таба да шулай талау дәвам иттереләчәк дигән сүз.

Талауга нәрсә керә соң? Түләүле медицина, түләүле югары уку йортлары, түләүле фатирлар, түләүле җир, салымнар, коммуналь-торак хезмәтләренә күтәрә алмаслык түләүләр һәм башкалар, һәм башкалар… Ә бөтен халык байлыгы булган нефть, газ халыкныкы түгел хәзер – скважиналары аерым кешеләр кулында булгач, ул байлык та аерым кешеләр кесәсендә ага. Халык боларның барысын да күреп тора, түрәләргә – чиновникларга нәфрәте арта. Әйе, хәзергә халык түзә әле, әмма моның бер чиге булмас дип, кем ышандыра ала?

**Әнисә ИСХАКОВА (ХӘМИДУЛЛИНА), хезмәт ветераны.**

# Кремльдә очрашу

РФ Президенты, «Бердәм Россия»нең эксбашлыгы В.В. Путин 19 июль көнне, үз вазыйфаларына керешкәннән бирле беренче тапкыр буларак, Кремльгә Дәүләт Думасының КПРФ, «Бердәм Россия», ЛДПР һәм «Гадел Россия» фракцияләре җитәкчеләрен чакырды. Очрашуда һәр фракциядән өчәр кеше, шул исәптән Компартиядән КПРФ Үзәк Комитеты председателе, халык-патриотик оппозициясе лидеры Г.А. Зюганов, Дәүләт Думасының беренче вице-спикеры, КПРФ ҮК председателенең беренче урынбасары И.И. Мельников, КПРФ ҮК секретаре һәм комсомол лидеры Ю.В. Афонин катнаштылар.



Очрашу барышын яктыртучы журналистлар президент белән дискуссияләрдә катнашу өчен Компартия җитәкчелегенә беренче тапкыр Коммунистик яшьләр союзы ҮК беренче секретаре Ю.В. Афонинның да катнашуын аерым басым ясап билгеләп үттеләр. Г.А. Зюганов аны партиядә үсеп килүче лаеклы яшь алмаш буларак тәкъдим итте. «Ю.В. Афонин шәхсән аның үзен алыштыра алырмы?» – дигән сорау да яңгырады очрашуда. КПРФ ҮК председателе бу сорауга җавап бирүне 2013 елның февралендә узачак XV партия съездына калдырды.


Г.А. Зюганов кискен политик проблемаларга карата КПРФ позициясен аңлатуны Краснодар краеның Кырым районындагы вакыйгаларга бәйләп башлап җибәрде.

«Хромая лошадь» төнге клубы, «Распадская» шахтасы, Саян-Шушенское ГЭСы, «Булгария» теплоходы, хәзер менә Кырым шәһәре – 500гә якын кешенең гомере өзелде. Бу фаҗигаләр өчен кемнәр җавап тотуын карадым мин. Нибары бер кеше – «Хромая лошадь» хуҗасына гына 6,5 ел бирделәр. Калганнарын җиңелчә өркетү белән чикләнделәр. Шуңа күрә дә без таләпчәнлекне һәм җаваплылыкны арттырырга кирәк дип саныйбыз, бигрәк тә кризис фонында, ә ул әле торган саен тирәнәя һәм катлаулана бара, моны без күреп торабыз».

«Думага сайлаулар турындагы законга да кичектергесез яңа төзәтмәләр кертергә кирәк. Без бит илне бергәләп торгызырга, бергәләп нычытырга җыенабыздыр? Ә яңа закон проектында үзәк исемлек кыскартыла. Һәркемгә, кем әйтмешли, үз сазлыгы – һәркем үзе булдыра алганча чупырдый. Бу партияләр түгел, ә удел белән идарә итүче князьлекләр. Бердәм, ныклы, көчле, акыллы, белемле, сәламәт партия дигән фикер үзе үк юкка чыга бара. Андый законны кабул итәргә ярамый. Ул илгә зыян сала», – дип нәтиҗә ясады КПРФ лидеры.

# Самара өлкәсе. Партактив семинары

26–27 май көннәрендә Тольятти шәһәрендә КПРФның Идел буе 14 региональ бүлеге партия активистларының ике көнлек семинары булып үтте. Семинарда КПРФ Үзәк Комитеты председателе урынбасары В.И. Кашин «Россиядәге политик хәлләр һәм КПРФ региональ бүлекләренең бурычлары һәм хәзерге шартларда партиянең башлангыч звеноларын ныгыту юллары һәм ысуллары турында» доклад ясады.



КПРФның Татарстан рескомы беренче секретаре Х.Г. Миргалимов республика парламенты депутат-коммунистлары Дәүләт Советында үз коллегалары – муниципаль берәмлекләр депутатларын әледән-әле җыеп сөйләшүне гамәлгә кертүләре турында хәбәр итте.

«Фракциянең барлык утырышларына да җирле бүлекләрнең секретарьлары чакырыла. Даими рәвештә пресс-конференцияләр үткәрелә. Депутатлар, башлангыч оешмалар секретарьлары белән берлектә, районнарда ай саен очрашулар үткәрәләр. Кешеләргә таяну үзенең уңай нәтиҗәләрен бирә дә инде. Мисал өчен, Татарстанда коммунистлар властьның ветераннарның юлда йөрүгә булган льготаларын «монетизацияләү» идеясеннән баш тартуына ирештеләр. Ә Юдино поселогында исә тимер юл начальнигы җирле халык мунчасыз да яши ала дип «хәл иткән» булган. Коммунистлар алынып, депутатлар ярдәме белән, протест акциясе уздырдылар. Хәзер бу поселокта менә дигән мунча эшли.

Кешеләр күреп торган конкрет эш – бүгенге көндә иң мөһиме», – дип йомгак ясады үз чыгышында Х.Г. Миргалимов.

**Рамил ГАЙФУЛЛОВ, КПРФ рескомы секретаре.**

# Әлмәттә 1056 кеше ВИЧ белән исәптә тора

Әлмәт шәһәренең СПИД үзәгендә ВИЧ-инфекцияле 1056 кеше исәптә тора. Узган атнада шәһәрдә һәм районда тагын 3 очрак ачыкланган, дип хәбәр итә «Әлмәт таңнары» газетасы.

Сәламәтлек саклау идарәсе хәбәр итүенчә, исәптә торучылар арасында 6 йөкле хатын-кыз бар, 17 бала да әлеге инфекциягә дучар булган.

**Роза ИСМӘГЫЙЛОВА.** («Татар-информ», 2.07.2012 ел).

# Оныкны бабайдан аердылар

1 май һәм 9 май бәйрәмнәре шаулап-гөрләп узды. Көннәр дә ярыйсы гына торды, халыкның кәефе дә күтәренке иде. Өчәр-дүртәр көн ял иттек. Ни хикмәт, Мәгариф һәм фән министрлыгы гына бу бәйрәмнәрдә «бер тәпән балга бер кашык деготь» өстәргә кирәк тапты. Мәктәптә укучы балалары булмаган кешеләр, эш нидә икән соң, дип уйлап куярга мөмкин.

Эш менә нәрсәдә: иртәгә 1 май һәм 9 май дигән көннәрдә балалар мәктәпкә укырга барырга мәҗбүр ителде. Бөтен ил бәйрәм итә, ә укучыларга ни гаепләре өчендер бәйрәм алды җәзасы бирелде. Алар да бу бәйрәмнәрне көтеп ала ләбаса. Әти-әниләре белән әби-бабалары янына кунакка барсалар, бәйрәм белән котласалар, бакчаларда эшләсәләр, инде бу дөньялыктан киткән туганнары каберлекләрен зиярәт итсәләр, гаилә традицияләре бозылмас, көчле тәрбия чараларыннан читтә калмаслар иде. Болай да тәрбия мәктәп эше генә булып калды. Балалар тәүлек дәвамында әти-әниләре, әби-бабалары белән ничә сәгать, яки ничә минут кына аралаша икән? Бу турыда дәүләт кайгыртмаса, бала яисә ата-ана кайгыртып кына ни эшли ала?



**Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ,** Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы журналистлар союзлары члены, ТРның «Мәгарифтәге казанышлары өчен» билгесе һәм «Алтын йөрәкле журналист» дипломы иясе.

# СЕМИНАР-КИҢӘШМӘЛӘР

**7–8 июль көннәрендә Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә КПРФның Татарстан региональ бүлеге партактивының зона семинар-киңәшмәләре булып узды.**

Киңәшмәләрдә рескомның беренче секретаре Х.Г. Миргалимов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул җирле бүлекләр секретарьларына КПРФ Үзәк Комитетының июнь ахырында Мәскәүдә узган XIII пленумы йомгаклары хәбәр итте, шушы ук пленумда партия лидерлары ясаган чыгышларда һәм пленум карарларында чагылыш тапкан хәл итәсе бурычларга һәм аларны чишү юлларына тукталды. Шулай ук Россиянең Бөтендөнья Сәүдә оешмасына керүенә бәйле проблемалар каралган, Дәүләт Советының КПРФ фракциясе инициативасы буенча үткәрелгән «түгәрәк өстәл» турында да әйтеп узды. Биредә шулай ук Дәүләт Думасында депутат-коммунист В.И. Бессоновка каныгу, агымдагы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советына өстәмә сайлалулар турында да сүз булды. Ул Апас районының 45-нче һәм Кукмара районының 47-нче бер мандатлы сайлау округларында көз көне 14 октябрьдә узачак.

– Без үз кандидатларыбызны тәкъдим итәргә ниятлибез, – дип, басым ясап әйтте Х.Г. Миргалимов.

Моннан тыш, КПРФ Үзәк Комитеты оештыру бүлегенең (Е.И. Газиев) «Партия бүлекләренең сайлап куела торган җитәкче органнарын «рейдерларча» яулап алу омтылышларына каршы тору чаралары турында» мәгълүматы таратылды. Документта, атап әйткәндә, түбәндәгеләр бәян ителә:

«Чынбарлык күрсәткәнчә, әхлакый күзлектән караганда, «рейдерларга» тәэсир итүнең бер файдасы да юк, чөнки алар үз максатларыннан башка бер генә моральне дә кабул итмиләр һәм танымыйлар. Шулай булуга карамастан, КПРФ Үзәк Комитеты бу мәсьәләдә читтән генә күзәтчелек итеп торучы статист сыйфатында кала алмый. «Рейдерлык»ны оештыру һәм үткәрү партия комитетлары сафларында бик каты тәнкыйтькә дучар ителеп, кырыс бәя алды инде. Якын киләчәктә әлеге мәсьәлә КПРФ Үзәк Комитеты Президиумында да каралачак».

## Хафиз МИРГАЛИМОВ: «Халыктан курыккан хакимият – көчсез хакимият»

Кичә ТР Дәүләт Советындагы КПРФ фракциясе үзенең ярты еллык эшчәнлегенә нәтиҗә ясады. Болай да алты гына бөртек булган коммунист-депутатлардан фракция җитәкчесе Хафиз Гаяз улы Миргалимов берүзе хисап тотты.

Депутат фикеренчә, Россия полиция дәүләтенә әйләнеп бара. Кеше бит яхшы тормыштан урамнарга чыкмый. Халыктан курыккан хакимият – көчсез хакимият. Штрафлар белән куркытып кына, проблемаларны хәл итеп булмаячак. Хакимият, киресенчә, халыкка якынаерга тиеш. Кырыс законнар исә кире нәтиҗә бирергә мөмкин.

Коммунистлар үзләрен халыкка иң якын партия дип саный һәм депутатларның парламентта эшчәнлеге дә нәкъ менә эшче-крестьян мәнфәгатьләре белән бәйле, диләр.

Ярты ел эчендә коммунист-депутатлар нәрсә кырды соң? Кайбер саннарга килсәк, фракция 5 утырыш, 4 «түгәрәк өстәл», 4 матбугат конференциясе уздырган. Аларның кайберләре хакында мәгълүмат биреп бардык инде.

Ә менә Президентка һәм Премьер-министрга депутат сорау-мөрәҗәгатьләре хакында сүз кузгатмаган идек. Алар җәмгысы 11 булып, унысы Х. Миргалимовныкы. Шул 11 сорауның 6сы «колакка элинмәгән». Бу ни дигән сүз? Коммунист-депутатлар йә тормышка ашмастай, йә дәлилсез мәсьәләләр күтәрәләрме? Әллә хакимият аларны коммунист булганга санга сукмыймы?

«Без проблеманы тирәнтен өйрәнмичә, дәлилләмичә мөрәҗәгать белән чыкмыйбыз», – диде Хафиз Миргалимов. Ни өчен Президентны һәм Хөкүмәт рәисен борчырга туры килә? Чөнки министрлыклар һәм ведомстволар үз эшләрен тиешенчә башкармый. «Отписка белән шөгыльләнәләр», – дип куйды Хафиз иптәш. Әйтүенчә, бу хәл коммунист-депутатларны гына түгел, ә парламент рәисе Ф. Мөхәммәтшинны да борчый. Инде хакимиятнең коммунистларга мөнәсәбәтенә килгәндә, ике арада зур дуслык юк. Кайбер районнарда узган утырышларда Х. Миргалимовка чыгыш ясарга мөмкинлек тә бирмиләр икән.

Депутат моны закон бозу дип бәяли. Аның әйтүенчә, бездә законнар 30 процентка гына үтәлсә дә, тормыш әйбәтләнер иде. Бу – буш сүзләр түгел. Әле тәүге тапкыр Президент тәхетенә утыргач, В. Путин да Россиядә закон диктатурасы урнашырга тиешлеген әйткән иде. Инде менә күпме сулар акты, Владимир Владимирович абруйлы һәм алыштыргысыз Президентка әйләнде, ә «закон диктатурасы» дигәннәре һаман да урнашып җитә алмый.

**Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ.**
(«Ватаным Татарстан», 04.07.2012 ел).

## Зюгановта – йөрәк авыруы?

КПРФ җитәкчесе Геннадий Зюганов дүшәмбе көнне хастаханәгә эләккән. Сәясәтченең сүзләренә караганда, аның хәле яхшы, ул волейбол уйнаганда аягын имгәткән. Коммунистлар лидерының Мәскәүдәге кардиология институтында дәвалануы гына шик уята. Аның хәле белән Путин һәм Медведев та шалтыратып кызыксынган. Интернет челтәрендә исә Зюгановның әлеге хастаханәгә эләгүен йөрәк авыруы белән аңлаталар. Кайбер мәгълүматларга караганда, КПРФ җитәкчесе инфаркт кичергән.

**«ВТ», 08.06.2012 ел.**

СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ

## Исемлектән төшереп калдырылды

Мине 2005 елны әйбәт эшләгәнем һәм район бәйрәмен яхшы оештырган өчен «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләгәннәр иде. Ул «Хезмәт ветераны» исемен алу өчен нигез була ала, димәк, пенсиягә чыккач, ташламалардан файдаланырга мөмкинлек бирә дип аңлаттылар. Ә беркөнне танышым, әлеге медальнең бернинди дә файдасы юк, диде. Имеш, ниндидер закон чыккан икән. Шул хакта аңлатсагыз иде, чынлап та ул хаклымы?

**З. Резеда. Казан.**

Республиканың Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында аңлатуларынча, РФнең «Ветераннар турында»гы законның 7 нче статьясы нигезендә, 2005 елдан башлап хезмәт ветераннары булып СССР яки Россия Федерациясенең орден яисә медальләре, шулай ук федераль дәрәҗәдәге ведомстволарның Мактау грамоталары яки күкрәк билгеләре белән бүләкләнгән кешеләр генә санала. «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале 2005 елда РФ Президенты Указы нигезендә булдырылган иде һәм 2010 елга кадәр ул, чынлап та, Россиянең дәүләт бүләге саналды, димәк, аның белән бүләкләнгән кешеләр «Хезмәт ветераны» исеменә лаек булды.

Әмма 2010 елның 7 сентябрендә «Россия Федерациясендә дәүләт бүләкләре системасын камилләштерү чаралары турында» Президент Указы (№1099) пәйда булды һәм аның нигезендә әлеге медаль ни өченде дәүләт бүләкләре исемлегеннән төшереп калдырылды. Шул сәбәпле, аның белән 2005 елдан башлап 2010 елның 7 сентябренә кадәр бүләкләнгән кешеләр генә «Хезмәт ветераны» исеменә өметләнә ала.

**«ВТ», 15.06.2012 ел.**

## Безгә дә кешечә медицина кирәк

Безнең Азнакай шәһәре һәм районында бик күп табиблар җитми. Хәзерге көндә терапевтка эләгү өчен дә берничә көн алдан язылып куярга кирәк. Кардиология бүлеге шәфкать туташлары 6-7 мең сум тирәсе хезмәт хакы ала. Ә санитаркалар 4-5 мең сумга эшләп йөри. Тикшеренә башласаң, аппаратлар юк, диләр. Мәсәлән, дозатор кайчан булыр? Палаталарда матраслар тузган, пычрак, урындыклар аз. Районыбызда халыкка тиешле медицина ярдәме кайчан күрсәтелер?

**Фәндәс ГӘРӘЕВ. Азнакай.**

Сораугa сәламәтлек саклау министры Айрат Фәррахов җавап бирә:

– Хезмәт хакы мәсьәләсенә килгәндә, медицина хезмәткәрләренә Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының 1999 елның 2 сентябрендә чыгарган 613 нче боерыгы нигезендә тариф челтәре буенча түләнә. Шуны да әйтергә кирәк: кардиология бүлегендә эшләүчеләр «2011-2012 елларда сәламәтлек саклау өлкәсен модернизацияләү» программасы буенча өстәмә акча ала. Җиһазлар һәм башка кирәк-яраклар тәэмин ителеше хакында район үзәк хастаханәсе җитәкчелеге менә ниләр хәбәр итә: «Кардиология бүлегенә аппаратлар һәм җиһазлар агымдагы елның икенче, өченче кварталында алыначак. Матрасларны, урын-җир әйберләрен ел сметасыннан чыгып ел саен яңартып торабыз. Быел да беренче кварталга беркадәр алдык инде. Әйе, башка районнардагы кебек бездә дә кадрлар кытлыгы бар. Азнакайга яшь белгечләрне тарту, аларны торак белән тәэмин итү җәһәтеннән район җитәкчелеге белән берлектә һәрдаим эш алып барыла. 5 яшь белгеч дәүләт торак фонды килешүе буенча фатирлы булды. Муниципалитет быел өченче кварталда җирле бюджет акчасына 3 табибка «служебный» фатир сатып алып бирүне планлаштыра».

**«ВТ», 25.05.2012 ел.**

# Кәгазьдә генә калмасын иде

Нальчиктагы «Туган тел» татар милли-мәдәни үзәге – Кабарды-Балкар Республикасы (КБР) территориясендә яши торган 3 меңләп татарның карап торган бердәнбер милли оешмасы. 2000 елның март аенда оешкан бу үзәк активистлары – төбәктәге татарларның рухи һәм милли традицияләрен барлауга, кайтаруга юнәлдерелгән күп кенә чараларда башлап йөрүчеләр. Күптән түгел миңа алар белән аралашып, хәл-әхвәл белешергә туры килде.

Төньяк Кавказга татарлар төрле сәбәпләр аркасында, төрле юллар белән килеп төпләнгән. Тарихчылар әйтүенчә, татарларның бу җирләргә килеп урнаша башлавына йөз елдан артып киткән инде. Татарларның күпләп күченеп килү вакыты – узган гасырның 20 нче елларына, Идел буендагы коточкыч ачлык чорына туры килә. Хәзер инде Төньяк Кавказ территориясендә чыгышы белән Әстерхан, Идел буе, Төмән, Себер, Урта Азия, Кырымнан булган татарлар яши, тамырлары Россиянең башка төбәкләренә барып тоташканнары да бар. Һәр төркемнең үз диалекты булса да, аларның һәркайсы үзен чын татар дип саный.

«Туган тел» мәдәни үзәге рәисе Сәидә Савченко (Фәхретдинова) Нальчикка лаеклы ялга чыккач ире Владиславның әти-әниләре янына күченеп килә. Аңа кадәр ул гаиләсе белән 25 ел Томскида яши. Сәидә ханымның үз әти-әниләре – Шәрифҗан Сафа улы Фәхретдинов белән Маһирә Ибраһим кызы Лютова – Куйбышев өлкәсендәге Иске Кулаткы районының Иске Атлаш авылыннан. Нәсел тамырлары турында Сәидә ханым болай дип сөйли:

– Әтием гаиләдә унөченче бала булып туган. Урта хәллеләр рәтендә яшәгәннәр, бик тырыш булулары белән аерылып торган. Сафа бабай үзе гаять кырыс кеше булган. Әтиемнәр ат, өч сыер асраганнар. Болгавыр елларда, аларны кулакка санап, терлекләрен тартып алганнар. 1933 елда әтием белән әнием ике бала белән Урта Азиягә китеп барган. Үзбәкстанның район үзәгеннән шактый еракта урнашкан бер кышлагына барып чыкканнар. Әти колхозда хисапчы булып эшли башлый. Тормыш җайга салынган кебек була. Балалар туа – 1936 елның сентябрендә мин дөньяга килгәнмен... Тик тыныч имин генә яшәп яту шатлыгы озакка булмый, Бөек Ватан сугышы башлана. Әтине фронтка алалар. Әнием кузгалып киткән состав вагоннарының берсеннән аның: «Ничек кенә булса да, балаларны укытырга тырыш. Фашистларны тармар итәчәкбез, җиңү безнеке булачак!» – дип кычкыруы турында сөйли иде.

Шулай итеп, бер әни җилкәсендә биш бала һәм аның картайган әнисе – Вәсби əбекәй кала. Ничек кенә кыен булмасын, без исән калдык, үстек. Әти вәсыятен истә тотып, барыбыз да югары белем алдык. Мин үзем Сәмәркандта Үзбәкстан дәүләт университетын тәмамладым. Мәктәптә биология һәм химия укытучысы булып эшләдем.

Ни кызганыч, безнең үсеп кеше булуыбызны әтиебез генә күрә алмады, сугыштан әйләнеп кайту насыйб булмады аңа. 1943 елның декабрендә «41 нче танк дивизиясе укчысы Шәрифҗан Фәхретдинов хәбәрсез югалды» дигән хат кына алдык...

Хезмәт ветераны Таһир Гыйниятуллин Көньяк Уралдан Нальчикка башта хатыны белән дәваланырга килә. «Безгә монда урыны да, һавасы да бик ошады, – ди ул, – шуңа да Төньяк Кавказга яшәү өчен дип, күченеп килергә уйладык». Медицина белеме булган бик күпләр, Казаннан килеп урнашкан Ирина Мрасова кебек, бирегә санаторийларда, бальнеология комплексларында эшләү өчен килеп, соңыннан төпләнеп үк кала икән.

Төрле язмышларга ия булган бу кешеләрнең барысын да Нальчиктагы «Туган тел» татар мәдәният үзәге берләштерә. Нәкъ менә шушы үзәк инициативасы белән Нальчикта 10 ел рәттән инде Сабан туе уздырыла. Традиция буларак, бәйрәм соңында җыелышып, милли ризыклар – чәкчәк һәм кош теле белән чәй эчәләр икән. Туган телне саклау, татар әдәбиятын һәм тарихын өйрәнү максатында, «Туган тел» тырышлыгы белән, 2003 елда Нальчикта татар якшәмбе мәктәбе эшли башлаган. Дәресләрне К. Мечиев исемендәге республика яшүсмерләр китапханәсе залында татар теле белгече Резедә Әхмәтнурова алып бара. Биредәге татар әдәбияты фонды Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Мәскәүдәге «Татар дөньясы» газетасы редакциясе һәм башка чыганаклардан алынган китаплар хисабына даими тулыланып тора.

Узган елның җәендә республиканың «Радуга» сәламәтләндерү үзәгендә татар мәдәнияте көне булып узган. Бу күркәм чараны КБРның Яшьләр эшләре һәм иҗтимагый берләшмәләр белән эшләү министрлыгы оештырган. Ял итүчеләр татар музыкасын, җырларын, шигырьләрен тыңлаган. «Танцы над Эльбрусом» фольклор фестивалендә, татар биюләрен башкарып, яшьләр I, II урыннарга лаек булган, бүләкләр алган.

Татар милли-мәдәни үзәгенә рухи яктан көч биреп, матди ярдәм күрсәтеп торучы төп таянычлары – республиканың танылган могтәбәр затлары: В. Коков исемендәге КБР Авыл хуҗалыгы академиясе профессоры Сәлим Искаков һәм Төньяк Кавказ дәүләт сәнгать институты профессоры, Россиянең халык артисткасы Наталия Гасташевалар. Тамырларында әнисе яклап татар каны аккан күренекле җырчы үзе дә татар телендә иркен сөйләшә, ул татар диаспорасына химаячелек ярдәме генә күрсәтеп калмый, аның эшчәнлегендә актив катнаша: төбәктә татар халык һәм профессиональ музыкасын пропагандалауга зур өлеш кертә. КБР татарлары Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы каршындагы «Идел» яшьләр үзәгенең дә ныклы ярдәмен тоеп яшәүләрен сөйләде. Үзәк яшьләрне фестивальләргә чакыра, нәкъ шундый чаралар барышында егет-кызлар үзара таныша, аралаша, дуслаша, хәтта гаилә коручылар да бар икән.

Нальчик татарларының бергә булырга, бердәм яшәргә, милли традицияләрне, халык йолаларын, гореф-гадәтләрен үтәргә тырышулары күзгә ташланып тора. Өйләнешәләр икән – никах мәҗлесе, бала туса, бәби туе уза, очрашулар барысы да милли ризыклардан авыз итү, чәй эчү белән тәгәлләнә.

Тик менә Нальчикта Татар милли-мәдәни үзәгенең әлегә кадәр үз бинасы юк. Шуңа күрә кайвакытта якшәмбе мәктәбендә туган телне өйрәнү дәресләре өзелә, үзешчән сәнгать, халык һөнәрләре, кул эшләре осталары түгәрәкләренең тотрыклы эшләве өчен дә шартлар юк; нәкъ шул сәбәптән яшьләр өчен татар телен өйрәтү курслары эшен башлап җибәрә алмыйлар. Диаспора активистлары Нальчик шәһәре хакимияте башлыгына бина сорап әллә ничә тапкыр мөрәҗәгать иткән. Үтенечләре һаман да кире кагыла, бинаны арендага алырга киңәш итәләр. «Туган тел» үзәге коммерциячел оешма түгел, моңа финанс мөмкинлекләре юк. Шуңа күрә алар Нальчикта да Казандагы «Халыклар дуслыгы йорты» кебек бина булсын иде дигән олы хыял белән яши.

«Элеккеге СССР шәһәрләренең бик күбесендә Муса Җәлил исемен йөртә торган проспектлар, урамнар бар. Без, Нальчикта яшәүче татарлар да, биредә Муса Җәлил исемендәге урам булуын телибез. Тик «Туган тел» исеменнән ничәмә-ничә тапкыр мөрәҗәгать итсәк тә, безнең үтенечне канәгатьләндермиләр, Муса Җәлил исеменең республикага катнашы юк, дигән җавап бирәләр», – дип борчылуын белдерде Сәидә ханым.

1999 елның 19 октябрендә үк инде КБР Парламенты тарафыннан «Кабарды-Балкария Республикасы белән Татарстан Республикасы арасында дуслык һәм хезмәттәшлек итү турындагы килешүне ратификацияләү турында» Закон кабул ителгән булган. Бу Килешү кәгазьдә генә калмас, тормышка ашырылыр дип ышанасы килә. Балалар да, яшьләр дә татар халкының тарихын өйрәнергә, мәдәниятен, рухи кыйммәтләрен, ата-бабалары мирасын барларга һәм белергә тели ләбаса. Алар рухи мәркәзебез булган Казанга зур өметләр белән карый.

**Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ.**
«ВТ», 07.07.2012 ел.

# САЙЛАУЛАР "ӘЙБӘТ" ҮТТЕ...

**Безнең илнең түрәләре һәр сайлау кампаниясеннән соң төрле җирдә үзләрен тынычландыра торган шундый рапортлар бирергә яраталар.** Аларның үзләре өчен генә түгел, нәсел дәвамчылары тормышы өчен дә сайлаулар хәлиткеч атрибутка әйләнде. Алар өчен иң мөһиме – нинди генә юл белән булса да, властьны кулдан ычкындырмау, ул инструмент кулда булса, аның белән ничек эш итәргә икәнен алар белә дә белә инде! Сайлауларның гадел узмавы Россиядә миллионнарча кеше күз алдында эшләнә. Шуңа күрә аны гадәти хәлгә әйләнгән бер хроник авыру кебек кенә кабул итәләр дә. Олыдан кубып беркем дә тавыш та чыгармый, тавыш чыгарырга маташучыларны тынычландырырга дәүләт органнары һәрвакыт әзер. Ни өчен дәүләткә ялган сайлаулар кирәк соң? Анда кемнәр хуҗа? Алга таба язылачак вакыйгалардан чыгып, сез үзегез нәтиҗәләр ясарсыз, хөрмәтле укучылар.

**Быелның 4 мартында Президент сайлаулары Актанышның 620-нче сайлау участогында да шома гына узып китми.** Сайлаучылар арасында оппозиция кандидаты Г. Зюганова өстенлек бирүчеләр күп була. Ә йомгаклау протоколында алар 20-дән артык итеп кенә күрсәтелә. Сайлаучылар моны белеп алгач, имзалар җыярга керешәләр. Без Г. Зюгановка тавыш бирдек диючеләр 50-дән артып китә. Бар кешене дә йөреп тормыйлар, йөрсәң ул сан күн саен арта тора һәм алар Г. Зюгановның ышанычлысына, ягъни әлеге язманың авторына мөрәҗәгать итәләр.

Мин үз чиратымда, җыелган имзаларны теркәп, К. Әмиров исеменә мөрәҗәгать язып, 26 март көнне аларны Татарстан прокуратурасына илтеп тапшырдым. Итагатьле генә алып калдылар. Шул атнада ук почта аша җавап та килеп ирешә: минем мөрәҗәгать Актаныш район прокуроры Р. Әскәровка җибәрелгән икән.

Район прокуроры алай ашыгып җавап бирмәде, чөнки бик мөһим мәсьәлә бит, ил башлыгы язмышына бәйле мәсьәлә хәл ителә, ашыгып ашка пешүең дә бар, 16 апрельдә генә ул төпле бер карарга килеп, имзасын сала: мөрәҗәгатьне Тукай районы тикшерү комитетына җибәрәм, диелә анда. Бер атна дигәндә Чаллы шәһәреннән, төгәлрәге Тукай районы тикшерү комитетыннан, җитәкчесе Р. Шипков имзалаган җавап килеп тә җитте. Минем мөрәҗәгать белән бергә, ниһаять, Актанышның күп санлы сайлаучылары имзалары сәяхәткә чыккан җиренә, ягъни туган Актаныш районы сайлау комиссиясенә әйләнеп кайткан икән. Шуның белән эш бетте дияргә дә була, Актаныш 3 ай инде җавап бирми.

**Бу хәлгә ачыклык кертүне сорап, Тикшерү комитетындагыларга да интернет аша гына хәбәр җибәрдем.** Алар мине бик зурлаганнар, конвертка салып хатлар юллаганнар, Мәскәүдән РФ Тикшерү комитеты эшне Татарстанга юллавы турында хәбәр итә. Казаннан да җавап килде, Тукай районы тикшерү комитеты мөрәҗәгатьне Актаныш район сайлау комиссиясенә җибәреп дөрес эшләгән дигән сүзләр бар анда. Ә Актаныш аерым хокукый зонамы әллә? Андагы законсызлыклар тикшерүгә тартылырга тиеш түгелмени? Шуның белән эшкә нокта куелган булып чыга түгелме соң? Сайлау законнарының бозылуына борчылучы юк. Дәүләт органнарын бу хәл бер дә борчымый икән. Әнә шундый борчылмый гына яшәп ятучы дәүләт оешмалары күпме бит бездә, ә аларда эшләүче меңнәрчә әрәмтамак дәүләт, ягъни халык байлыгын кимереп ята булып чыга түгелме?! Илнең бата баруында аларның эше юк.

Закон бозу турында сигналлар хокук саклау органнарында әнә шулай салкын битарафлыкка юлыгы беркемгә дә сер түгел. Теләр-теләмәс кенә эшләүчеләр өчен дәүләт күп чыгымнар тотып, аларга уңайлы яшәү шартлары булдыра. Ә ил алга китми, тегендә үтереш, монда катастрофа. Халык белән власть арасында упкын. Гаделсезлекне дәүләт органнарының күрмәмешкә салышуы бер хәл, гадел эшләр өчен әзәрлекләү гадәти хәлгә әйләнде. Алга таба әзәрлекләүләр турында.




**Декабрь (2011) һәм март (2012) айларындагы сайлаулар барышында активлык күрсәткән кешеләр әзәрлекләүләргә дучар ителделәр.**

Бу уңайдан **Ринат Шәфигуллин** менә ниләр сөйли:

Оппозицион партияләрнең берсенең тәкъдиме белән мин президент сайлауларында, хәлиткеч тавышка ия булып, 543-нче номерлы участок сайлау комиссиясе членлы буларак катнаштым. Нәтиҗәләр гадел булыр дигән өмет бар иде, чөнки участокта видео-теркәгечләр дә урнаштырылган иде бит. Әмма «могҗизалар» сайлау көнендә үк башланды: ЛДПР, «Гадел Россия» һәм «Бердәм Россия» партияләре күзәтүчеләре барысы да «таныш һәм үз кешеләр» булып чыкты. Бирегә шәһәр хакимияте вәкиле дә, «Азнакайнефть» идарәсе («Татнефть» ААҖ бүлекчәсе) кешесе дә, мин эшли торган ПРС цехы вәкиле дә бар иде. Барысының да бурычы бер булып чыкты: Путинның 96 процент тавыш җыеп җиңүенә ирешү.

Барысы да комиссия эшендәге «вактөяк хаталарга» игътибар биреп тормаска үгетләүдән башланды. Миңа бу рәвешле басым ясауның файдасы юк икәнен аңлагач, даими психологик басымны «эшкә җиткеләр», шантаж, сатып алырга маташу да булмый калмады: 5 мең сум акча тәкъдим итүдән башлаганнар иде, йорт төзү өчен җир участогы «бирүгә» кадәр барып җиттеләр!

2012 елның 22 марты көнне «Азнакайнефть» идарәсе ПРС цехының белдерүләр тактасында цех начальнигы Р. Сабиров имзасы куелган мондый боерык барлыкка килде:

«Хезмәтне саклау кагыйдәләре таләпләре буенча белемнәрне чираттагы тапкыр тикшерү вакытында ПРС операторлары белемнәренең канәгатьләнерлек булмавы ачыкланды. Тикшерү нәтиҗәләреннән чыгып, карар бирәм:

Хезмәтне саклау кагыйдәләрен тиешенчә белмәгән өчен ПРС операторлары Н.Т. Муллаевның, Р.Г. Әхмәдуллинның, Р.С. Шәфигуллинның, И.Ф. Шәвәлиевның 2012 елда март ае өчен премияләрен 25 процентка киметергә».

Ягъни 2012 елның 4 марты көнне участок сайлау комиссиясендә эшләгәннәрнең премияләре киселгән! Муллаев – 542-нче участок сайлау комиссиясендә хәлиткеч тавышка ия булган член, Әхмәдуллин – 537-нче участокта КПРФтан күзәтүче, Шәфигуллин – 543-нче участок сайлау комиссиясендә хәлиткеч тавышка ия булган член, ә Шәвәлиев 529-нчы участок сайлау комиссиясендә хәлиткеч тавышка ия булып торган членның улы!

542-нче участок сайлау комиссиясендә КПРФтан хәлиткеч тавышка ия булган член **Наил Муллаев** сөйли:

22 сәгатьтә йомгаклау беркетмәсенә кул кую өчен бар нәрсә дә әзер иде инде, әмма комиссия председателе башта минем белән «сөйләшеп алу кирәк» дип тапты, чөнки ул бу участокта Путинга «кирәк кадәр тавыш җыелмады» дип саный иде. «Азнакайнефть» идарәсе начальнигы урынбасары миңа сайлаучыларның Миронов, Прохоров, Жириновскийны яклап биргән тавышларының бер өлешен Путинга «шудырырга» тәкъдим итте. Ул инде сайлауларга кадәр үк башта үз кабинетына чакырып, ә икенче көнне мин дежур торган чакта сайлау участогында да басым ясарга тырышып караган иде. Ул мине «Татнефть» җәмгыятенең политикасына каршы килүче дип атады һәм бу оешманың «кара исемлегенә» әләгүемне әйтте.

556-нчы участок сайлау комиссиясендә КПРФтан хәлиткеч тавышка ия булган член **Илшат Хәйдәров** сөйли:

1997 елда мин «Азнакайнефть» идарәсе ПРС цехына оператор булып эшкә урнаштым. Сәламәтлегем какшау сәбәпле, 2011 елда 2-нче разрядлы ярдәмче эшче булып күчерелдем. 2012 елның президент сайлауларында 556-нчы сайлау участогында эшләргә ризалык бирдем. 4 марттагы тавыш бирү көнендә цех начальнигы участок сайлау комиссиясе эшендә күзәтүче булып шәхсән үзе утырды һәм көн буена колагыма әледән-әле фальсификациягә ризалашсам, разряд та, яхшы хезмәт хакы да булачагын тукып торды. Ризалашмыйм икән – түзеп тора алмаслык шартлар тудырачакларын әйтте. Әмма мин бу сүзләргә колак салмадым.

Җаваплылыгы чикләнгән «Татбуртранс» җәмгыятенә менә мондый фактка юл куелган. Декабрьдә (2011) үткән сайлауларда **Ринат Сәләхов** 521-нче участок сайлау комиссиясендә КПРФтан хәлиткеч тавышка ия булган член буларак катнашты. Участокта сайлау нәтиҗәләре искитмәле булган – КПРФ өчен 35,06 процент тавыш җыелган! 26 гыйнвар көнне КПРФның җирле бүлеге шәһәрнең территориаль сайлау комиссиясенә алдагы сайлауларда эшләү өчен участок сайлау комиссиясе составына кертергә дип, үз кандидатларының исемлеген тәкъдим иткән иде. Территориаль сайлау комиссиясенең 3 февраль көнне чыгарган карары нигезендә исемлекне распаганнар. Моның өчен 2 февраль көнне Сәләховны хезмәт хакы түбәнрәк булган эшкә күчереп, аннан «үч алганнар».

**Болардан соң ирексездән бер сорау туа: демократия уены уйнау кемгә отышлы?** «Ялган» сайлауларга бүлеп бирелгән акчаны бәлки инвалидларга, ятимнәргә, пенсионерларга һәм башка мохтаҗ кешеләргә генә өләшеп чыгаргады? Депутатларга бу мәсьәләне конкрет хәл итәргә вакыт җитмәдеме? Парламентарийларның күпчелеге намуслы юл белән сайланып куелган икән, алар сайлауларда законнардан тайпылу юлларын ябып бетерергә күптән тиешләрдер бит инде?! Мондый сайлаулар депутатларның күпчелеген канәгатьләндерә икән, димәк аларның ничек итеп бу югары урынга кереп утыруларын чамаларга була. СССРны саклап кала алмадык, хәзерге депутатлар белән Россияне саклап кала алырбызмы?

**Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ,**
**РФ Дәүләт Думасы депутаты ярдәмчесе.**

# Пенсия яше кемгә аз?

Соңгы вакытта, пенсиягә чыгу яше арта, дигән сүзләр йөри. Моңа карата халыкта төрле фикер бар. Гомер буе авыр физик хезмәт башкарган кешеләр өчен бу бик куаныч хәл түгел, әлбәттә. Ә менә җыелы булмәдә генә утырып, эшләгән кыяфәт чыгарып йөргән җитәкчегә пенсиягә чыгу яше аз тоела кебек. Танышым Саша абый зарын тыңлаганнан соң шундый фикер туды. Ул кышкы суыкларда интегеп машина кабызуын, юлда күп тапкыр ватылып байтак тилмерүен сөйләде.

– Ягулык исен, машина тәтенен сулап пенсиягә чыкканда, сәламәтлек калмаган иде! Безнең өчен аның 60 яше дә бик күп әле, – ди ул.

Ә ул эшләп чыккан Азнакай УТТ (технологик транспорт идарәсе) коллективында, пенсия яше җиткәч тә эшен дәвам итүчеләр бар икән. Президент сайлаулары алдыннан Саша абыйның өенә шул оешма җитәкчесе А.Попов белән профсоюз рәисе А. Ганиев килә. Максатлары – В. Путинны сайларга кирәклеген төшендерү. Ул аны сайлаган очракта, матди ярдәмгә һәм моңарчы күп тапкырлар йөреп тә ала алмаган юлламага да (шифаханәгә) өметен өзми яши алачак икән. Ә китәр алдыннан Александр Петрович, кичке якта «картлач»ка пакет белән күчтәнәч тә китерергә кушып, профсоюз җитәкчесенә әмер бирә. Атлас Ганиев, аның аркасыннан сөя-сөя:

– Кич белән киләм, абзый, – дигәч, «картлач» эреп китеп, В. Путинны сайларга да вәгъдә биреп ташлый.

Ләкин кич тә, иртән дә килүче генә булмый.

– Кәтә-кәтә яккан мунчама да керә алмадым, суынып бетте. Бер ышандыргач, барып В. Путинны сайладым инде, – ди Саша абый. – Мин ул пакетка калмаган, ләкин Азнакай УТТсының ике пенсионеры (теге җитәкчеләр турында әйтүе) эш вакытын сарыф итеп, башка пенсионерларны алдап, бимазалап йөрүе күңелемне рәнҗетте.

Әгәр һәр оешмада җитәкчедән башлап, гади эшчегә кадәр вакытны дөрес файдаланып, чын күңелдән бирелеп эшләсә, беркем дә пенсия яшен арттыру турында уйламас иде, дип фикер йөртә Саша абый. Чыннан да, оешмасын, файдаланылучы техникаларын торышын һәм эшче мәнфәгатьләрен чын күңелдән кайгырткан җитәкченең мондый «шөгыльләргә» вакыты калыр иде микән?!

**Равил АХУНОВ. Азнакай шәһәре.**
**(«Безнең гәҗит», 6.06.2012 ел).**

**Барлык почта бүлекләрендә дә «ПРАВДА» газетасына язылырга мөмкин.**
**Газетаның индексы: 50102.**
**Ярты елга язылу бәясе: 634,44 сум.**

«Татарстан коммунисты» («Коммунист Татарстана»)
Баш редактор – Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ
Техник редактор – Евгений РУЛЕВ
Телефон: 9600623230, факс: (85592) 7-56-46
Электрон адрес: ursai55@rambler.ru,
www.kprf.ru («Коммунисты и российское общество»)

Газетаның учредителе: КПРФның Татарстан региональ бүлеге.
Учредитель һәм редакциянең адресы: 420021, Казан шәһәре, Сул Болак урамы, 56.
Тел./факс: (843) 292-53-26, 292-27-22.
Газета Элемтә, информацион технологияләр һәм күмәк коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республика идарәсендә ПИ №ТУ 16-00314 таныклыгы белән 19.02.2010 елда теркәлде.
Басарга кул кую вакыты: график буенча – 20.07.2012 ел, 10.00, кул куелды – 10.00.

«Бөгелмә типографиясе» ААҖ
423230, РТ, Бөгелмә шәһәре,
Карл Маркс урамы, 32
Телефон: (85594) 4-85-49
Заказ 302. Тираж 10000.
Бәясе ирекле.